... ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СӘБЫЙ ПАК НУР БЕЛӘН..

# Яшь каләмче

*октябрь 2024*

*Яр Чаллы шәһәре 40 нчы урта гомуми белем бирү*

## 5 ОКТЯБРЬ
## УКЫТУЧЫЛАР КӨНЕ

### ГАЗЕТАБЫЗНЫҢ БУ САНЫ ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗГА БАГЫШЛАНА

**Бәйрәмегез белән, мөхтәрәм укытучыларыбыз!**

**С праздником, уважаемые наши учителя!**









**Укытучысыз кеше булмый**

Укытучысыз кеше булмый,
Ул - һава кебек кирәк.
Укытучың булмаганда
Тибүдән туктый йөрәк.

Фикерләүдән туктый башың,
Күзеңдә сүнә нурлар.
Тормышта туктап каласың,
Өзелә барыр юллар.

Укытучысыз яшәп булмый,
Теләгем сезгә шушы:
Максатка юл күрсәтердәй
Табылсын укытучы!

**Раил Гатауллин.**

**Укытучым**

Һәр карашың - гыйлем нуры синең,
Һәр сүзеңдә синең изгелек.
Әнидер син, бәлки,
Без дә синең
Бәгыреңнән төштек өзелеп.
Тактадагы акбур белән язган
Һәрбер җөмлә безнең күңелдә.
Мең галимнән якты йолдыз булып
Балкыйсың син белем күгендә.
Галимнәр дә галим була алмый,
Шагыйрьләр дә шагыйрь түгел лә, -
Син утырткан гүзәл гөлчәчәкләр
Шытып чыкмый калса күңелдә.
Әнидер син, бәлки,
Без дә синең
Бәгыреңнән төштек өзелеп.
Укытучы булу - Фәрештәләр
Язып бетерә алмас изгелек!
**Рифат Сәлах.**

**Укытучы**

Уч төбенә куеп Җирне гүя,
Бүгенгесен аның, үткәнен
Күрсәтте ул безгә...
урап кайттык
Күрелмәгән илләр үтәли.
Аяз дөнья, кешелек бәхете өчен
Көрәшергә безне өндәде:
— Яратыгыз Җирне! — диде
һаман,
Ләкин:
— Мине яратыгыз! — димәде.
Аңа бүген еллар аша карыйм:
Көлеп басып тора күңелдә...
Ах, хәйләкәр абый!
Җирне, кешеләрне яраттырып
Яраттырган икән үзен дә!
**Рәдиф Гаташ.**




***Мыслители всех времён подчеркивали высокое общественное значение учителя. «Сеятели разумного, доброго, вечного» – говорят об учителях.***
***От них – всё лучшее в человеке.***

В Древней Руси складывалось искреннее почтение к учителю. **«…Он был отцам отец и учителям учитель… неложный учитель, добрый пастырь, праведный учитель, неподкупный наставник…».**

«Учитель влияет на вечность: никогда нельзя быть уверенным, где кончается его влияние» — (Генри Адамс).

*А вы знали, что в Татарстане пять памятников, посвященных учителям?*

*Самый первый из них появился в 2010 году в Кировском районе Казани во дворе школы №67. Инициаторами его возведения стали педагоги, родители и ученики школы. Памятник представляет из себя стелу высотой 2,5 метра.*

***В 2011 году памятник учителю появился в Буинске. Монумент в виде раскрытой книги установили напротив детского сада «Веселые нотки», который только открылся в тот год. Деньги на возведение памятника учителю собирали местные жители.***

***В 2018 году перед зданием управления образования в Балтасях памятник учителю поставила территориальная профсоюзная организация Общероссийского Профсоюза образования. На постаменте – бронзовая учительница возле школьной доски. На татарском языке слова благодарности всем учителям района за воспитание и обучение детей.***

***Еще один памятник учителям, но уже военным, установили в столице республики в 2021 году. Скульптурная композиция находится около суворовского военного училища.***

***Последним появился мемориальный комплекс, посвященный учителям в городе Азнакаево. На трех стелах увековечены имена заслуженных педагогов района, в том числе учителей, участвовавших в Великой Отечественной войне.***

***Совсем скоро на Казанской набережной появится также сквер Учителя, где разместят павильон, амфитеатр, зону для интерактива, тематические арт-объекты и скульптуру.***









# Боекмас өчен күңелләр, кимсемәс өчен йөрәк-сез кирәк, укытучылар, безгә һәрчак сез кирәк!






*Минем яраткан укытучыларым.*

*Укытучы - ул бик хөрмәтле кеше. Чөнки ул балаларга белем бирә, аларны бер сүздән аңлый, һәрвакыт ярдәмгә килә.Безнең мәктәптә күп укытучы апалар укыта. Минем яраткан укытучыларым Тәскирә Халитовна, Ирина Юрьевна,Алсу Нәкыйповна,Рузалия Рәвгатовна .Укытучыларым дәресләрне бик яхшы аңлаталар, матур сөйләшәләр. Алар мәрхәмәтле, сабыр, акыллылар. Безне әти-әнигә ярдәм итәргә өйрәтәләр, олыларны хөрмәт итәргә тиешлекне аңлаталар. Бу укытучыларыма бик зур рәхмәт, чөнки алар көчләрен кызганмыйча, безнең өчен тырышып эшлиләр.*

*Бәйрәм белән сезне,укытучыларым!* ***7а сыйныфы, Шәкурова Рәминә***



Минем яраткан укытучым.

Укытучы - иң катлаулы һөнәрләрнең берсе. Укытучы һәр кешенең тормышында мөһим роль уйный. Минемчә, укытучы булу җиңел түгел. Ул һәр бала белән уртак тел таба белергә тиеш.

Минем яраткан укытучым - Людмила Александровна. Ул дәресләрне бик кызыклы итеп үткәрә. Людмила Александровна белән һәрвакыт мәктәптән тыш тормыш турында да сөйләшергә мөмкин.Минем укытучым ачык күңелле, акыллы һәм гадел. Ярый әле мондый укытучылар бар.

Барлык укытучыларымны да бәйрәм белән котлыйм! **7д сыйныфы, Закирова Айзилә**



Хөрмәтле, яраткан укытучыларым! Сезне һөнәри бәйрәмегез белән котлыйм. Сезнең һөнәрегез бик затлы. Сез безгә дөньяны танып-белергә өйрәтүче кешеләр. Һәр укучының сәләтен, талантын ачарга сез ярдәм итәсез.Укучыга белем бирү өчен сездән күп көч, сабырлык һәм мәхәббәт таләп ителә. Сез укучыларыгызның уңышларына үзегезнекенә караганда да күбрәк шатланасыз.


Яраткан укытучыларым, мин сезгә чиксез рәхмәтлемен. Эшегездә уңышлар, ныклы сәламәтлек, илһам телим. Укучыларыгыз иң рәхмәтле, иң яхшы, иң акыллы, игелекле булсыннар. Рәхмәт сезгә! **7д сыйныфы, Сафинә Зәлинә.**



*Кадерле укытучыларым!*
*Сезне бәйрәмегез белән котлыйм. Безне күп нәрсәгә өйрәткәнегез өчен рәхмәт. Сезгә ныклы сәламәтлек, иминлек телим.*
***7д сыйныфы,***
***Ахметханов Тимур***



*Минем хөрмәтле укытучыларым!*
*Барыгызны да укытучылар бәйрәме белән котлыйм.*
*Белем биргәнегез өчен барыгызга да рәхмәт. Сезгә сәламәтлек, бәхет телим. Һәрвакыт шулай игелекле булып калыгыз.*
***7д сыйныфы, Габбасов Данир***



Барлык укытучыларымны да бәйрәм белән котлыйм!
Безгә белем, тәрбия биргәнегез өчен сезгә зур рәхмәт,
7д сыйныфы,
Айсылу Кәримова



*Безнең мәктәптә игелекле, үз һөнәренә тугрылыклы укытучылар эшли.*
*Минем иң яраткан укытучым, сыйныф җитәкчем - Тәскирә Халитовна. Ул бик игелекле һәм ярдәмчел укытучы. Авыр минутларда һәрвакыт барлык балаларга да ярдәм итәргә әзер.Укытучыбыздан без фән буенча белем генә түгел, ә тормыш тәҗрибәсе да алабыз. Без барыбыз да Тәскирә Халитовның яраткан укучылары. Ул безнең иң яхшы укытучыбыз.*
*7а сыйныф, Шарапова Ралина*

# КаМАЗ-55лет.




# Это интересно!

*Давайте вспомним самые яркие достижения автогиганта*

«КАМАЗ» образован в 1969 году как Камский комплекс заводов по производству большегрузных автомобилей (производственное объединение «КамАЗ»).

Первый автомобиль сошёл с главного сборочного конвейера 16 февраля 1976 года.

*- За всю свою историю КАМАЗ выпустил более 2,3 млн грузовых автомобилей и около 3 млн двигателей. Каждый третий грузовик полной массой 14-40 тонн в России и странах СНГ – это КАМАЗ*

*- Согласно статистике КАМАЗа сегодня на предприятии работает более 35 тыс. человек. Это почти столько же, сколько проживает в небольшом европейском государстве Монако*

*- КАМАЗ – звезда мирового автоспорта. Команде «КАМАЗ-Мастер» исполнилось 36 лет. Это единственная в России заводская команда, успешно представляющая страну в мировом автоспорте.*

## День КаМАЗа в нашей школе.

**«КАМАЗ» провёл очередное профориентационное мероприятие в нашей школе Сотрудники КАМАЗа организовали День «КАМАЗа»**

По традиции День «КАМАЗа» начался с подведения итогов предварительных творческих конкурсов. Ребята представили на суд жюри интересные работы. Большинство рисунков на тему «КАМАЗ – машина будущего» отличались своей яркостью и эмоциональностью, а макеты и творческие проекты на тему «КАМАЗ – транспорт для всех» были представлены в зелёном цвете и ориентированы на защиту Отечества. Смелость мыслей и полёт детской фантазии были безграничны. Все участники творческих конкурсов получили ценные призы, а победители – памятные подарки.

Организаторы постарались, чтобы все дети были задействованы в мероприятиях. Чтобы максимально увлечь ребят, задания были подготовлены под каждую возрастную группу . Ребята с интересом прошли все этапы познавательного мероприятия и в награду получили магниты и ручки с логотипом «КАМАЗа , блокноты и сладости.

## Фоторепортаж с праздника















**“Яшь каләмче” түгәрәге**